Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Ямаш авылы җирлеге Ямаш авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

3 август 2026 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2026 елның 3 августында 18 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән белән түбәндәге «Сез Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге бюджетына 2025 елда 100 000 сум 00 тиен күләмендә кергән гражданнарның үзара салым акчалары "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Ямаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2024 елның 28 ноябрендәге 7 номерлы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Ямаш авылында 2025 елга гражданнарның үзара салымын кертү турында» 8 номерлы карарларына нигезләнеп, "су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, тезү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (су белән тәэмин итү линиясен алмаштыру); торак пункт территориясен төзекләндерү (тукталыш павильоны территориясен сатып алу һәм төзекләндерү); яктыртуны, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру (урам яктырту фонарьларын сатып алу һәм урнаштыру)" өчен билгеләнгән әлеге акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә «су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны һәм халыкка су бирүне (су белән тәэмин итү линиясен алмаштыруны), торак пункт территориясен төзекләндерүгә» юнәлдерү белән килешәсезме? соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 450 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 280 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 280 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Ямаш авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге бюджетына 2024 елда 100 000 сум 00 тиен күләмендә кергән гражданнарның үзара салым акчалары "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Ямаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2024 елның 28 ноябрендәге 7 номерлы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Ямаш

авылында 2025 елга гражданнарның үзара салымын кертү турында» 8 номерлы карарларына нигезләнеп, "су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (су белән тәэмин итү линиясен алмаштыру); торак пункт территориясен төзекләндерү (тукталыш павильоны территориясен сатып алу һәм төзекләндерү); яктыртуны, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин иту һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру (урам яктырту фонарьларын сатып алу һәм урнаштыру)" өчен билгеләнгән әлеге акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә «су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны һәм халыкка су бирүне (су белән тәэмин итү линиясен алмаштыруны), торак пункт территориясен төзекләндерүгә» юнәлдерү белән килешәсезме? турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Ямаш авылы, Советская урамы, 109А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ямаш авыл җирлеге башлыгы Е.С.Ларин